**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ЧЕРЕМШАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Улица М.Титова, дом 7, село Черемшан, 423100 М.Титов урамы, 7 йорт, Чирмешән авылы, 423100
тел./факс 8(84396) 2-52-30 email: Cmn.Cmn2@tatar.ru

**31.01.2024** **№ 1**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең
хакын раслау турында**

1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм күмү эше турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты нигезендә (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында «Күмү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» һәм 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы «Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитеты мәсьәләләре» карарлары, «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 23 гыйнварындагы 46 номерлы карары нигезендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе җирле үзидарә органнары белән Россия Федерациясе Пенсия фонды, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды бүлекләре белән, шулай ук Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары белән (Тарифлар буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты – алга таба Дәүләт комитеты) килештерү буенча билгеләнә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән

исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2023 елның 27 гыйнварындагы 3 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе М.Д.Шәйхетдинов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
башкарма комитетының
2024 елның 31 гыйнварындагы
№ 1 карарына

2024 елның 1 февраленнән
ТР Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
**бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (*сум.*)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3043,25 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1392,90 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3934,05 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
башкарма комитетының
2024 елның 31 гыйнварындагы
№ 1 карарына

2024 елның 1 февраленнән
ТР Чирмешән муниципаль районының Чирмешән авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең
**бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 319,59 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2723,66 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1392,9 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3934,05 |
| **Барлыгы** | **8370,20** |